ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
**19.05.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**БОЕРЫК**
**№ 03-04-19**

Юл буе сервисы объектларында җәмәгать туклануын оештыруны контрольдә тотуны көчәйтү турында

Азык-төлек белән агулану һәм массакүләм эчәк инфекцияләре барлыкка килү очракларын булдырмау максатында, Татарстан Республикасы территориясендә юл буе сервисы объектларында җәмәгать туклануын оештыруны контрольдә тотуны көчәйтү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2017 елның 10 февралендәге ПР-37 номерлы йөкләмәләре исемлеген үтәү

1.Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлегенә 2017 елның апреленнән сентябренә кадәрге чорда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Кулланучылар базары бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының ТР Зеленодольск районы бүлеге (килешү буенча), ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Зеленодольск территориаль органы (килешү буенча) белән бергә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү буенча эшчәнлек алып баручы хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлегенә контрольне көчәйтүне тәкъдим итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге тарафыннан 2017 елның 15 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына һәм Зеленодольск муниципаль Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә башкарылган эшләр турында мәгълүмат бирергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С. Анисимовка 2017 елның 15 октябренә кадәрге срокта, азык-төлек продукциясен җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларга юл куйган оешмаларны күрсәтеп, уздырылган чаралар нәтиҗәләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)сайтында урнаштырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контроль тотуны үз җаваплылыгымда калдырам калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин